ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.04.2024 ел Баулы шәһәре № 49

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 31 октябрендәге 1377 номерлы «Дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы, 2020 елның 25 маендагы 118 номерлы, 2021 елның 2 ноябрендәге 195 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 245 номерлы, 2022 елның 4 июлендәге 125 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 278 номерлы, 2023 елның 12 маендагы 118 номерлы, 2023 елның 24 августындагы 170 номерлы, 2023 елның 24 августындагы 170 номерлы, 2023 елның 27 ноябрендәге 219 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган, Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

VI «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр» бүлегендәге 6.4. пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән

өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгеләре булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмәләр Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

«Стимуллаштыручы характердагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы (Совет Социалистик Республикалар Берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы) ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәгә 1-нче кушымтаны 1.20 - 1.26 пунктчалары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «1.20. | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22. | «Фидакарь хезмәт һәм аерым уңышлар өчен» медале |
| 1.23. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга керткән өлеше өчен» медале |
| 1.24. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Почетлы хезмәткәре» исеме |
| 1.25. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының Мактау грамотасы »; |

Күрсәтелгән карар белән расланган, Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

V «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр» бүлегендәге 5.4. пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгеләре булган өчен өстәмәләр Татарстан

Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

«Россия Федерациясе ведомство (тармак), Татарстан Республикасы (Совет Социалистик Республикалар Берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы)» бүләкләре» бүлегенең 1-нче пунктында күрсәтелгән Нигезләмәгә 1 кушымтада, 1.20. - 1.26. пунктчалары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «1.20. | «Почетлы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22. | «Фидакарь хезмәт һәм аерым уңышлар өчен» медале |
| 1.23. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга керткән өлеше өчен» медале |
| 1.24. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Почетлы хезмәткәре» исеме |
| 1.25. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының Мактау грамотасы »; |

Күрсәтелгән карар белән расланган, Баулы муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

VI «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр» бүлегенең 6.2.2. пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгеләре булган өчен өстәмәләр Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

1-нче таблицаның «Россия Федерациясе ведомство (тармак), Татарстан Республикасы (Совет Социалистик Республикалар Берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы)» бүләкләре» бүлегенең 1 нче пункты күрсәтелгән Нигезләмәгә кушымтада, 1.18 -1.24. пунктчалары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «1.18. | «Почетлы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.19. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.20. | «Фидакарь хезмәт һәм аерым уңышлар өчен» медале |
| 1.21. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга керткән өлеше өчен» медале |
| 1.22. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Почетлы хезмәткәре» исеме |
| 1.23. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.24. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгының Мактау грамотасы ». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров